**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**Алькеевского**
**муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әлки**
**муниципаль районы**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Базарлы Матак авылы **КАРАР**

2022 елның 11 октябре 372№

2023 елга “Әлки муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең балаларга өстәмә белем бирүче туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге мәгариф оешмаларының һәм балаларга өстәмә белем бирүче күппрофильле мәгариф оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында

2012 елның 29 декабрендәге "Мәгариф турында" 273-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законының 99 нчы статьясы, 2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 нче статьясындагы 1нче өлешенең 11нче пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 31 декабрендәге “Татартан Республикасында балаларга өстәмә белем бирүче туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге мәгариф учреждениеләрен һәм балаларга өстәмә белем бирүче күппрофильле мәгариф учреждениеләрен финанслау нормативларын исәпләү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында" 939 номерлы карары һәм “Әлки муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2023 елга расларга:

“Әлки муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең балаларга өстәмә белем бирүче туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге мәгариф оешмаларының һәм балаларга өстәмә белем бирүче күппрофильле мәгариф оешмаларының норматив чыгымнарын;

балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында балаларга туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге өстәмә белем бирү оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирү күппрофильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнарга карата төзәтү коэффициенты 0,5 күләмендә.

2. «Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Финанс-бюджет палатасына тәэмин итәргә:

әлеге карарның 1нче пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә балаларга өстәмә белем бирү буенча мәгариф оешмаларын финанслауны;

әлеге карарның 1нче пунктында расланган Балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары чоры дәвамында хезмәт законнарында һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла торган өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакын индексацияләү белән бер үк вакытта яңадан карауны.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2023елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга, Әлки муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

"Әлки муниципаль районы" муниципаль
берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе: Р.Х.Морадымов

Расланган
«Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең 2022 елның 11 октябрендәге 372 номерлы карары

**“Әлки муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең балаларга өстәмә белем бирүче туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге мәгариф оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирүче күппрофильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыру өчен НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАРЫ**

| Өстәмә белем бирү программасының юнәлеше | Территориаль урнашуы | Норматив чыгымнар, 1 укучыга, 1 елга, сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | беренче уку елы | икенче уку елы | өченче һәм аннан соңгы уку еллары |
| Сәнгать-эстетик | авыл җирлеге | 8 251 | 15 280 | 18 336 |
| Физик тәрбия-спорт | авыл җирлеге | 8 150 | 15 093 | 18 111 |
| Техник иҗат | авыл җирлеге | 8 555 | 15 842 | 19 011 |
| Туристлык-туган якны өйрәнү | авыл җирлеге | 8 352 | 15 467 | 18 561 |
| Экология-биология | авыл җирлеге | 8 352 | 15 467 | 18 561 |
| Хәрби-патриотик | авыл җирлеге | 8 352 | 15 467 | 18 561 |
| Социаль-педагогик | авыл җирлеге | 7 948 | 14 718 | 17 661 |
| Социаль-икътисади | авыл җирлеге | 7 948 | 14 718 | 17 661 |
| Табигый-фәнни | авыл җирлеге | 8 352 | 15 467 | 18 561 |